Азнакай районы Туйкә авыл жирлеге башлыгының
2017 ел эш нәтиҗәләре буенча отчеты

Хәерле көн,  Айдар Халяфетдинович, килгән кунаклар, авылдашлар!

«Туйкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Татарстан Республикасы Дәүләт Советының  2001 ел 27 июнендә чыккан № 879 карары нигезендә оешкан. Җирлеккә  Туйкә, Камышлы Күл, Карамалы-Елга  авыллары керә.

2018  елнын 1 январенә  272 хуҗалыкта 569 кеше яши: Туйкә авылында 184 хужалыкта – 466 кеше, Камышлы Күл авылында 48 хуҗалыкта – 54 кеше, Карамалы-Елга  авылында  40  хуҗалыкта – 49 кеше.

2017 елда җирлегебездә   2   бала туды,   5  кеше үлде.

Социаль хәле буенча: пенсионерлар –  149 кеше; - эш яшендәгеләр - 329 кеше;  балалар – 98.

Авыл җирлеге Советы үзенен эшен Устав нигезендә депутатлар белән берлектә төзелгән планнар буенча алып бара. 7 округта 7 депутат бар, шуларнын 2 се район советы депутаты да булып тора. 2017 елда авыл җирлеге советында 14  утырыш уздырылган, анда 33 сорау каралган. Нигездә законнар үзгәрү сәбәпле Уставка үзгәрешләр кертү, бюджет буенча, положениеләр кабул итү,  башка төрле норматив- хокукый актларга үзгәрешләр кертү,  һәр елны кабатлана торган чараларны:  9-Май, сабан туйлары, һәм башка бәйрәм чараларын оештыру, территорияләрне чистарту мәсьәләләре каралды. Кабул ителгән карарлар нигездә үтәлеп баралар.

2017 елда халыктан 6 язмача мөрәҗәгать кабул ителде. Барлык мөрәжәгатьләр дә канәгатьләндерелде,  аларга  вакытында жавап бирелде.

Туйкә авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан  ел эчендә халыкка 195 справка бирелде.

Ай саен Военкомат бүлегенә, бердәм хисап үзәгенә (ЕРЦ) үзгәрешләр бирелә, гражданнарны паспортлары нигезендә учётка алу, учеттан төшерү, хуҗалык китабына даими үзгәрешләр кертү (бу шулай ук электрон рәвештә алып барыла) һәм башка бик күп   эшләре башкарыла. Болар барысы да муниципаль хезмәт күрсәтүгә керә.

№ 258 - Федераль Закон нигезендә 2017 елда халыкка 31 нотариаль хезмәт күрсәтелде.

Бүгенге көндә авыл җирлегендә яшәүче халыкның яхшы яшәве өчен барлык мөмкинлекләр бар: һәрбер өйгә газ, электр кергән.

Җирлектәге халыкка  1 фельдшер-акушерлык пункты – Туйкә авыл халкына хезмәт күрсәтә, Камышлы Күл, Карамалы-Елга авылларына Балтач фельдшер-акушерлык пункты хезмәт күрсәтә. , 1 магазин, китапханә һәм мәдәният йорты, балалар бакчасы эшләп килә.

Фельдшер-акушерлык пункты 466 кешегә хезмәт күрсәтә, аларның 244 хатын-кыз, 222- ир-ат. 14 яшькә кадәр балалар- 80, яшүсмерләр- 11.

Туйкә авылы балалар бакчасына 10 бала йөри, быел тагын 1 бала киләсе бар. Балалар бакчасында 6 кеше эшли.

Бинага капиталь ремонт кирәк.

Туйкә авылы китапханәсенең фонды- 4296 китап. 216 кеше китапханәгә йөри, шуның 51 - балалар. 2017 елда 3775 китап бирелгән, шуларның - 975 балаларга.

Авылыбызның Мәдәният йорты хезмәткәрләре халыкка тиешле дәрәҗәдә мәдәни хезмәт күрсәтү, җирлегебез талантларын барлау, халкыбызның борынгы гореф-гадәт йолаларын кире кайтару, төрле кичәләр һәм бәйрәмнәрне күңелле итеп үткәрүне максат итеп эшлиләр.

Полиция оперуполномоченные Хабипов Ильнар Ленар улы безнең белән шулай ук һәрвакыт элемтәдә булып, мөрәҗәгать булганда ситуация буенча һәрчак оператив эшли.

Шәхси хуҗалыкларның житештергән продукциясенең үзеннән арткан өлешен сату- шәхси - ярдәмче хуҗалыкларның финанс хәлен яхшыртуга зур терәк булып тора. Сөтне Балтачтан Хабипов Илгиз җыя. 2017 елда Туйкә авылы халкыннан 41 мең 87 литр литр сөт җыелды. Күп савым сыер тотучы Сәгитов Марат белән Маннанов Мөҗәһит сөтләрен үзләре илтеп тапшыралар.

Җирлегебездә халык нигездә мөгезле эре терлек асрау белән шөгыльләнә. 2017 елның 1 январенә шәхси хуҗалыкларда барлыгы 196 мөгезле эре терлек булып, шуларның 61- ен савым сыерлар тәшкил итте.

Шулай ук шәхси хуҗалыкларда 233 сарык, 112 кәҗә, 9 ат, 87 куян, 1346 кош-корт асрала, 172 баш умарта тотыла.

2017 елда Республика бюджетыннан җирлектәге сыер асраучы хужалыкларга бер сыерга 3000 сум исәбеннән, бер савым кәҗәгә 1000 сум күләмендә субсидия таратылды.

Туйкә авыл җирлеге халына 56 савым сыерына, 50 кәҗәгә субсидиялар таратылды.

Авыл жирлеге башкарма комитеты бюджетыннан шәхси хужалыгында 6 баш савым сыер асраучы Ногманов Дамирга 22 мең 500 сумлык саву аппараты бирелде.

Шәхси ярдәмче хуҗалыкларны һәм кече эшмәкәрлекне үстерү өчен Республикабызда күп төрле программалар эшләп килә:

Кызыксынган кешеләр тулырак мәгълүмат өчен авыл җирлеге башкарма комитетына һәм Азнакай районы авыл хуҗалыгы идарәсенә мөрәжәгать итә ала. Шулай ук Азнакай районы башкарма комитетында эшмәкәрлекне үстерү буенча махсус вазифа алып баручы белән берлектә эшләргә мөмкин.

Җирлекнең үзидарә органы структурасына җирлек Советы, җирлек башлыгы, җирлек башкарма комитеты, җирле үзидарәнең башка органнары керә. №131 - Федераль Законы һәм Устав нигезендә урындагы әһәмияткә ия булган төп мәсьәләләрне хәл итү өчен муниципаль берәмлекләргә 13 вәкаләт беркетелгән:

авыл җирлекләрен чисталыкта тоту һәм яшелләндерү, урам утлары белән тәэмин итү;

- халыкны су белән тәэмин итү;
- юлларны төзекләндерү, кардан чистарту;
- зиратларны карау;
- буаларны карау;
- пожар куркынычсызлыгы белән тәэмин итү, һәм башкалар.

Бу вәкаләтләр буенча эшләр барысы да республикадан бирелүче дотация, трансфертлар һәм кергән салымнар хисабына башкарыла. Салым Кодексы нигезендә авыл җирлекләре бюджетына җир һәм милек салымы, физик затларның керем салымы, организацияләрнең җир налогы керә. 2017 елда бюджетка 4 миллион 724 мең 600 сум керем керде: 38,9 мең сум физик затларнын керем салымы, 57,6 мен сум милек салымы, организацияләрдән- 4 миллион 260 мең сум җир салымы, халыктан -141,4 мен сум жир салымы, 197,5 мең сум үзара салым, нотариаль хезмәтләр күрсәтүдән- 5 мең 600 сум.

Җирлегебездә төзекләндерү чаралары буенча традицион эшләр узган елда да башкарылды. Урамнарда, зиратларда, эш урыннарында чисталык өмәләре уздырылды. Елдагыча урам баганаларын агарту, һәйкәлләрне ремонтлау кебек эшләр башкарылды. Камышлы Күл авылында, авыл активистлары башлап йөреп , анда мәчет төзелә башлады.

Җәйге чорда авылыбызның чисталыгын кайгыртып, Бикбулатов Сабир Туйкә авылын жыештырып, чүп үләннәрен чабып торды.

Гомумән алганда, бүгенге көндә авылда яшәүчеләрнең ихтыяҗы зурдан: яхшы юллардан йөрисе, социаль объектлардан файдаланасы килә. Бу - җирле властьнең төп бурычы, ягъни безнең эш.

Чисталык барыбыз өчен дэ кирәк: чистарткан җирдә түгел, ә чүпләмәгән җирдә чиста була диләр. Чисталык, төзекләндерү чараларын үтәүнең әһәмияте турында халыкка һәрдаим аңлатып торылса да, ихата тирәләрендә чүп үсүче хаҗалыклар бар. Тагын бер тапкыр исегезгә төшерәбез: ихата тирәләрен, бакча артларын чиста тоту- һәр хуҗалыкның бурычы.

Авыл жирлекләрендәге чүплекләрне ябу сәбәпле, каты көнкүреш калдыкларын җыю буенча хезмәтне Азнакай «Полигон ТБО» оешмасы күрсәтә. Полигон ТБО күрсәткән хезмәтләргә түләүне вакытында түләп баруыгызны сорыйбыз. Вакытында түләмичә, 2-3 мең сум бурыч җыйган гаиләләр дә бар безнен Туйкә авылында. Тагын бер кат искәртеп, бу бурычларны түләп бетерүегезне сорыйбыз.

Авыл җирлегендә ут линияләре, светильниклар иске булу сәбәпле, баганаларда лампочкалар еш янып чыга. Ел дәвамында 5 светильник өстәп куелды, 17 янган лампочка алыштырылды. Беребезнең дә караңгыда яшисе килми. Бу эшләрне башкару өчен, махсус оешмадан вышкалы машина чакыртабыз, аның берничә сәгать эше 5-6 мең сум тора.

Кышкы чорда юллар үз вакытында чистартылып тора. Азнакай автомобиль юллары идарәсенә караган юллар- Туйкә авылында мәдәният йортына кадәр- бу школьный автобус маршруты, Камышлы Күл һәм Карамалы-елга авылларында- авылга кадәр юллар һәркөн КамАЗ белэн чистартылып тора. Авыл җирлегенә караган юллар, килешү нигезендә чистартылып торалар.

Үзара салым буенча да әйтеп үтәсе килә.

Иң башта җирлегебез халкына рәхмәт сүзләре әйтәсе килә. Үзара салым акчаларын халык вакытында түли. Безнең Туйкә авыл җирлеге үзара салым акчасын районда беренчеләрдән булып җыеп тапшырабыз.

2017 елда халыктан 197 мең 500 сум үзара салым акчасы акча җыелды. Шушы акчага Республикадан (1 сумга 4 сум хисабыннан) 790 000 сум субцидия акчасы кайтты. Бу акча түбәндәге эшлэргэ тотылды:

1) Туйкә авылында асфальт юлларны ремонтлау- 100 мең сум;

2) авыл эчендәге юлларга таш ташытып, җәйдерү- 100 мең сум;

3) авыл эчендәге юлларны кышкы чистарту- 70 мең сум;

4) Туйкә, Камышлы Күл авылларының су линияләрен ремонтлау- 200 мең сум;

5) Туйкә авылы зиратының ритуаль йортын ремонтлау, Карамалы-Елга авылы зиратының коймасын алыштыру- 250 мең сум;

6) балалар мәйданчыгы төзү- 267,5 мең сум.

Һәрбер ел узенен истәлекле вакыйгалары белән истә калган кебек, 2018 ел да Россия президентын сайлау белэн истә калачак. 18 март - Россия Президентын сайлау көне. Илнен алга таба яшәешенә нык бэйле булган сайлаулар безнен жирлектә дә әйбәт кенә узар дип ышанасы килә.

Тормышта иң мөһиме - тынычлык. Әгәр дә тынычлык була икән, эш тә бара, балаларны да үстереп була, башка мәсьәләрне хәл итәргә дә, планнар төзергә дә була. Шуңа күрә бу сайлауларны матур итеп үткәрик. Россия дөнья күләмендә үзенең сүзен әйтергә тырыша. Әлбәттә, ул күп илләргә ошамый. Әмма Россия көчле булырга тиеш. Россия эшенә бер кеше дә тыгылырга тиеш түгел. Шуңа күрә, илебезгә көчле лидер кирәк. 18 март көнне сайлауларны дөрес итеп үткәрергә тиешбез

Сайлауларга бару һәр кешенең ил алдындагы олы бурычы, дип саныйм. Тынычлык, иминлек турыдан-туры җитәкчеләрнең хезмәтенә бәйле. Шулай булгач, сайлауларга барып үз тавышыңны бирү һәркем өчен мөһим.

18 март конне барчагызны да сайлау участогына килеп, үзегезнен конституцион хокукларыгыздан файдаланып һәм гражданлык бурычын үтәп, илбашын - Россия Президентын сайлау буенча тавыш бирергә чакырам.

Чыгышымны тәмамлап шуны әйтәсе килә:

- җирлегебезгә, безнең мөрәҗәгатьләргә игътибары очен Азнакай муниципаль районы башлыгы Шайдуллин Марсель Зуфаровичка, анын командасына һәм барлык җитәкчеләргә,
- авыл җирлегендә хезмәт куючы барлык хезмәткәрләргә, җәмәгать оешмалары җитәкчеләренә,
- авылның көн-күрешенә битараф булмаган җирлегебез халкына аңлашып эшләгәнебез өчен зур рәхмәт.

Алдыбызда торган алдагы еллар, уңышлы, имин еллар булсын. Беребезгә дә күрелмәгән кайгы-хәсрәтләр күрергә язмасын. Авылларыбызда халык бүгенге кебек тыныч, матур тормышта яшәсен. Барыбыз да сау-сәламәт, бәхетле булып, шат күңел белән матур тормышта яшик.

Игътибарыгыз өчен рәхмәт!